Декабрь • 2020 ел • № 6 (36)
minem-gimnaziyam.jimdo.com

# Минем гимназиям

2 нче ГИМНАЗИЯ

«М. Вахитов исемендәге 2 нче гимназия» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе газетасы



# Котлы булсын, Яңа ел!

Тагын бер ел үтеп китте. Америка язучы Леонард Луис Левинсон сүзләре белән әйтсәк: «Бүген сиңа ничек яхшы булуын иртәгәге көн тумыйча аңламыйсың». Бер ел элек беркем дә безгә нинди сынаулар аша үтәргә туры киләчәген күз алдына да китерә алмый иде. Узып баручы ел үз эченә берничә ел йөген алган кебек тоелды. Ул һәрберебез өчен гаиләдәге якыннарыбызның сәламәтлеге өчен борчылулар, уку-имтиханнар тапшыру өчен эчтән янулар, үзара аралашу мөмкинлегеннән аерылып торулар, ишетеп-күреп белгән кешеләрне югалтулар белән авыр булды. Ләкин узып баручы ел авырлыкларны җиңеп чыгуга өметләр белән дә бәйле булды. Батырлык, ярдәмчеллек һәм шәфкатьлелек – безнең йөрәкләрдә, характерда һәм гамәлләребездә булганга күрә, без бу авырлыкларны җиңеп чыктык.

Безнең иң беренче җиңү – бик кыска вакыт аралыгында гимназиягә яхшы ремонт ясау. Белем бәйрәменә килгән мөхтәрәм кунак Татарстан сәясәтчесе, Татарстан Дәүләт Шурасы спикеры Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин, әле күптән түгел генә укучыларның ашханәдә туклanulары белән кызыксынган Татарстан Республикасы президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов та гимназиядә укучыларга белем бирү өчен тудырылган шартлардан канәгать калуларын белдерделәр. Гимназия чиста, матур, зәвыклы дизайн белән бизәлгән.

Быелгы вәзгыятьне исәпкә алсак, безнең гимназия бик нәтиҗәле эшли. Без дистантта булган барлык укучыларга да психологик һәм, әлбәттә инде, педагогик ярдәм күрсәттек. Аларга ничек авыр булуын әле булса искә алабыз, чөнки укытучыларыбыз оператив төстә яңача эшләүгә күчте. Моның өчен аларга «5»ле!

Дистанттан соң балаларның ничек итеп мәктәпне, укытучыларын, сабакташларын сагынуларын күреп торабыз. Педколлектив та мәктәптә балалар белән узган һәр минутның кадерен белергә өйрәнде.

(Ахыры икенче биттә.)



*(Ахыры. Башы беренче биттә.)*

2020 ел авырлыклары белән бергә зур уңышлар, иҗади җиңүләр һәм казанышлар алып килде. Безнең 2 укучыбыз узган уку елында рус теле буенча БДИны 100 баллга язды! Шулай ук World Skills Халыкара эшче профессияләр конкурсының юниорлар арасындагы «Инженерлык дизайны», «Челтәрле һәм системалы идарә итү» компетенцияләрендә 6 балабыз катнашып, призлы урыннарга лаек булды. Туган татар телендә узучы олимпиада, бәйгеләр, конкурслар бик нәтиҗәле булды. Безнең гимназия «Татарстан Республикасы муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында туган телдә белем бирүнең иң яхшы тәҗрибәләре» республика бәйгесе җиңүчесе булды һәм биш йөз мең сум күләмендә грант отты. Укытучылар арасында узган һөнәри бәйгеләрдә: «2020 елның иң яхшы психологы», «Иң яхшы татар теле укытучысы», «Укытучы-эксперт» бәйгеләрендә җиңүчеләр булу безнең өчен горурлык .

Хәер, бик тиз үткән кебек тоелса да, күңелле, истә калырлык вакыйгалар да, сынаулар да хәйран күп булган икән быел безнең тормышта.

Пандемия белән бәйле кыенлыкларга карамастан, без, татар теле укытучыларының педагогик тәҗрибәләрен туплап, «Татар әдәбиятыннан дәрестән тыш эшчәнлек» дигән методик кулланма чыгардык.

«Минем гимназиям» газетасы мәктәп яңалыкларын яктыртып барды, укучыларның иҗади язмаларын киң даирәгә җиткерде. Укучылар кебек үк, мин дә, газетаның һәр санын көтеп алып, кызыксынып укыдым һәм укыйм.

Мин, коллективыбыз исеменнән, барыгызны да 2021 ел белән тәбрик итәм! Яңа 2021 елда бөтен укытучыларга, укучыларга сәламәтлек телим! Бу – иң мөһиме. Бүгенге көндә табиблар гына түгел укытучылар да геройлар. Пандемия чорында укытуның авырлыгын алар үзләре генә белде. Укытучылар үзләре дә иң кирәкле, иң игелекле һөнәр сайлауларын һәрдаим белеп торсын. Укучылар, сыйфатлы белем алуларына сөенеп, яңадан-яңа уңышка ирешсеннәр иде. Бу елның сезгә бик күп бишләләр, лаеклы җиңүләр һәм ышанычлы дуслар алып килүен телим!

**Айдар Хәкимҗан улы ГАРИФУЛЛИН,**
*М.Вахитов исемендәге №2 гимназия директоры*



# Бәхетле Мизгелләр

Соңгы көннәрдә минем өчен бик шатлыклы вакыйгалар булды. «Глаголица» бәйсез әдәби премия бәйгесендә катнашуым зур уңышка китерде. Финалга чыккан йөз укучы арасында мин дә бар идем. Татарстаннан гына түгел, Россиянең төрле төбәкләреннән килгән балалар белән бергә, мин биш көн буена «Счастливые истории» фонды оештырган, Казан шәһәренең «Дуслык» лагерендә булдым. Бүлмәдәшләрем арасында Балтач районыннан, Санкт-Петербургтан, Мәскәү, Вологда өлкәләреннән килгән яшь каләм сөючеләр бар иде.

Биш көн буена без күп кызыклы чараларда катнаштык, әйдаманнар оештырган төрле квест уеннар аеруча ошады. Без көн саен Казан шәһәре буйлап төрле күренекле урыннарда сәяхәт кылдык.

Максим Горький, Федор Шаляпин музейлары белән таныштык, изге Кол Шәриф мәчете, «Туган авылым» комплексы, Казан федераль университеты минем күңелемә аеруча ошады. Балалар язучылары Андрей Усачев, Сергей Махотин белән очрашуда алар үзләренең иҗаты белән таныштырдылар. Иҗади мастер-классларда төрле фотографияләр, брелоклар ясау серләре белән таныштык, мин истәлеккә берничә сувенир ясап алып кайтып, әниемә, энемә бүләк иттем.

Мин татар прозасы номинациясендә катнашып җиңгән идем. Татар язучылары үткәргән мастер-класслар минем күңелемдә аеруча истә калды. Ркаил Зәйдулла, Рөстәм Галиуллин, Галимҗан Гыйльманов, без – финалистларның эшләрен анализладылар. Минем «Булат маҗаралары» исемле әсәрне тикшереп:

– Молодец, Айзат, бик әйбәт язгансың! – дигәч, минем кәефем тагын да күтәрелеп китте.

Безнең бер буш вакытыбыз да булмады диярлек, һәрвакыт иҗади эшләр белән шөгыльләндек. Кичләрен дискотекада биеп, күңелле ял иттек.

Менә дулкынландыргыч көн килеп җитте. 20 нче ноябрь көнне без «Әкият» курчак театры бинасына бүләкләү тантанасына җыелдык. Бу бинаның тышкы кыяфәтен күрү белән чынлап та үзебезне әкият дөньясына кергән кебек сиздек. Искиткеч матурлыкка сокландык.

Йөз кеше арасыннан 30 дипломант исеме билгеле булуын түземсезлек белән көттек. Казанга бу көнне тантанага әти-әнием, энем дә килгәннәр иде. Алып баручылар җиңүчеләрне игълан иткәндә, йөрәгем дөп-дөп тибә иде.

– Гайнетдинов Айзат, Яр Чаллы шәһәре, – дип хәбәр ителгәч, сөенечемнең иге-чиге булмады, йөгереп сәхнәгә мендем. Язучы, әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь Галимҗан абый Гыйльманов кулыннан бүләк алу минем өчен зур дәрәҗә булды. Миңа җиңүче дипломы, китаплар җыелмасы һәм планшет бүләк иттеләр.

Казанда узган бу биш көн хәтеремдә яңа дуслар, кызыклы очрашулар белән гомергә истә калыр. Алдагы елларда да мондый бәйгеләрдә катнашырга уйлыйм.

**Айзат ГАЙНЕТДИНОВ,**
*2 нче гимназиянең 5 в сыйныфы укучысы*

# Кызлар бокстан куркырга тиеш түгел



Гөлшат Салахованың үзенчәлекле спорт төре белән шөгыльләнүен белгәч, һичшиксез миндә кызыксыну артты, Гөлшаттан интервью алырга булдым. Әлеге әңгәмәне сезгә дә тәкъдим итәм.

*– Гөлшат, син спорт белән күптән шөгыльләнәсеңме?*

Гөлшат: Дүртенче сыйныфта укыганда, мин спорт төрләреннән чаңгыда шууны үз иттем. Инде биш еллык тәҗрибәм бар.

*– Димәк, синең бокска килүең очраклы күренеш булмаган, син спортның тәмен татыган булгансың.*

Гөлшат: Әйе, мин организмымны чыныктырырга, ныгытырга, көчле, матур булырга телим. Бокс белән шөгыльләнүемә икенче ел китте.

*– Кызык, ни өчен боксны сайларга булдың?*

Гөлшат: Әлеге спорт төре кызлар арасында никтер популяр түгел, минем шуның киресен исбатлыйсым килә. Ул бик үзенчәлекле спорт төре бит.

*– Үзенчәлеге нәрсәдә икәнен киңрәк аңлатып уз әле?*

Гөлшат: Бокс спортчыдан фикерләү рәвешендә һәм хәрәкәт итү тәртибендә игътибар таләп итә, син, бер адым ясаганчы , икенче адымыңны уйларга тиеш.

*– Димәк, син «җыелып бетәргә» кирәк. Күктән йолдызлар санарга күнеккән кызлар эше түгел инде ул бокс.*

Гөлшат: Әйе , бокс минем характерымны күпкә үзгәртте. Мин спортзалда бөтен тискәре эмоцияләремнән арынып кайтам.

*– Тискәре эмоцияләр дигәндә, нәрсәне күздә тотасың?*

Гөлшат: Кайчагында үзеңнән , дәресләрдә алган билгеләрдән канәгать калмыйсың, анысы да була.

*– Синең бу шөгылеңне сыйныфташларың ничек кабул итә?*

Гөлшат: Мин һәр кеше үз язмышын үзе сайлый , дип уйлыйм. Сыйныфташларымны мин хөрмәт итәм, алар да миңа карата шундый ук мөнәсәбәттә.

*– Атнасына ничә тапкыр шөгыльләнәсең?*

Гөлшат: Көн саен диярлек, быел имтиханнар бирәсе булгач, чәршәмбе, җомга көннәрен бушатырга туры килде.

*– Кайсы спорт клубына йөрисең?*

Гөлшат: Олимпийскийга. Шәһәрдә өч спорт клубы бар.

*– Синең белән бергә башка кызлар да шөгыльләнәме?*

Гөлшат: Без өч кыз. Үзара конкурентлык бар инде ул, ләкин без дуслар.

*– Бокс ул бит материал чыгымнар да сорый торган спорт төре.*

Гөлшат: Әйе, Аллага шөкер, минем әти-әнием мине аңлыйлар, һәрвакыт ярдәм итәләр, әгәр дә алар аңламасалар, берүземә авыр булыр иде. Әтием үзе дә спорт белән шөгыльләнә, әнием балалар бакчасында тәрбияче. Аларны мин бик яратам.

*– Ярышлар алдыннан борчыласыңмы?*

Гөлшат: Әлбәттә, бер-ике көн кала бигрәк тә дулкынланасың.

*– Көндәшеңнән куркасыңмы?*

Гөлшат: Башлап киткәнче, бер кат җиңелчә борчылу хисе була инде. Аннан нишдидер үзеңне саклау, һөҗүм итү теләге туа. «Мин синнән көчлерәк бит, нигә мин җиңелергә тиеш», – дип уйлыйм.

*– Тренерың кем? Ул синнән канәгатьме?*

Гөлшат: Терентьев Владимир Леонидович. Әлбәттә.

*– Уңышларың бармы?*

Гөлшат: Әйе, узган ел һәм быел 2005–2007 елгы кызлар арасында бокс буенча Республика беренчелегендә икенче урын алдым. Мин бик сөендем.

*– Бокс белән шөгыльләнәчәксеңме, әллә вакытлыча гына мавыгумы?*


Гөлшат: Юк, мин әлеге спорт төрен үз иттем, яраттым.

*– Син бик чибәр кыз бит, борыным сынар, я булмаса башка зыян килер, дип курыкмыйсыңмы?*

Гөлшат: Кызлар бокстан куркырга тиеш түгел!

*– Рәхмәт, Гөлшат, эчкерсез җавапларың өчен, сине уңышың белән тагын бер кат котлыйбыз. Алга таба яңа үрләр яуларсың , дип ышанабыз.*

**Алия НУРИСЛАМОВА**






# Чын дуслык

Үзенең салкын көннәре белән кыш та килеп житте. Ул бөтен җирне үзенең ап-ак юрганы белән каплады. Урманнардагы агачлар да шәрәләнеп калды, тик чыршы агачлары гына үзләренең ямь-яшел күлмәкләрен киеп утыралар. Бөтен урам чыр-чу килгән балалар тавышы белән яңгырап тора. Алар рәхәтләнеп тауда чана, чаңгы шуалар. Битләре алсуланган, күңелләре күтәренке!

Ике якын дус – Ләйсән белән Ләйлә – чаналарын сөйрәп, тауда шуарга чыгып киттеләр. Алар бик озак шудылар. Тик китәр вакыт җиткәч, Ләйлә: «Мин тагын бер генә җилдереп төшәм әле», – дип, таудан тагын бер элдертеп кенә шуып төшәргә уйлады. Менә сиңа бәла, чана әйләнеп капланмасынмы? Үтереп аяк авырта. Чыдар әмәл юк. Авыртуга түзә алмыйча, ул дусты Ләйсәнне чакырды, тик ахирәте генә: «Мин ашыгам!» дип китеп барды. Ләйлә дустыннан мондый хәлне көтмәгән иде, аның күзләренә яшь тыгылды.

Дөнья яхшы кешеләрсез түгел шул! Ләйләнең хәлен күреп, якында чана шуып йөрүче чит кыз янына килеп басты. Ул аны кулын биреп бастырмакчы булды, тик Ләйлә баса алмады. Кыз югалып калмады, ярдәмгә зуррак балаларны чакырып китерде. Шулай итеп, Ләйләне чанага утыртып, өйләре янына алып кайттылар. Аннан аның әнисен чакырып чыгардылар һәм тиз арада ашыгыч ярдәм машинасына шалтыраттылар.

Табиб Ләйләнен аягы сынганын әйтте һәм аның аягына гипс салды. Ләйлә мәктәпкә йөрмәде. Ләйлә дустын бик көтте, гафу итәргә дә әзер иде, ләкин Ләйсән күренмәде. Аягы төзәлеп, мәктәпкә чыккач та Ләйсән дус кызын күрмәмешкә салышты. Күпләргә үрнәк булган дуслык шулай эреп юкка чыкты.

Чын дуслык әнә шундый авыр хәлләрдә беленә шул ул...

## Яңа ел

Эх, Яңа ел, Яңа ел!
Яңа ел безгә килә.
Кыш бабай үзе белән
Бүләкләр алып килә.
Әбине һәм бабайны,
Энемне дә онытмый.
Әтине һәм әнине
Без бүләксез калдырмыйк.
Чыршыбызны бизәдек,
Салатлар да ясадык,
Дусларны да чакырып,
Яңа ел каршыладык.
Бик кызык булды безгә!
Бәйрәмнәр бик тиз үтә,
Ярар инде борчылмыйк,
Сигезенче март җитә!

**Ләйлә ГАЛИМҖАНОВА,**
*4а сыйныфы*





# Тылсымлы уклар

Яшәгән ди, булган ди, бер әби белән бабай. Аларның Тимерхан исемле уллары булган, ди. Егет ай үсәсен көн үсеп, батыр булып буйга җиткән, ди. Шулай беркөнне карт аңа җәя белән өч ук бирә: «Улым, син инде чын пәһлеван булып үсеп җиттең! Без инде бик картайдык. Син бар, бәхетеңне эзләргә юлга кузгал. Менә сиңа җәя һәм уклар. Бу уклар өчәү генә, тик гади түгелләр. Алар – тылсымлы. Сиңа юлыңдагы киртәләрне юк итәргә булышырлар», – ди.

Тимерхан юлга кузгала, карурманнар аша уза, биек тауларга менә, тирән елагалар гизә. Шулай бара торгач, арып-талгач, хәл алырга дип, бер агач төбенә утыра. Еракта, тау башында бик зур затлы сарайны күреп ала. Шул яктан искән җил белән бер җыр ишетелә. Егет түзми, агач башына кунган сандугачтан сорый: «Әй сандугачым, нинди моңлы тавыш ишетәм мин!» – ди.

Сандугач, телгә килеп, бәйнә-бәйнә сөйли башлый: «Ул сарайда явыз дию пәрие яши. Ул анда Сылуны бикләп тота. Сылу көн саен шулай моңаеп җыр суза», – ди.

Егет аны коткару теләге белән сикереп тормакчы була. Тик сандугач янәдән: «Юк, егет! Бик күпләр Сылуны коткарырга теләделәр, тик кире әйләнеп кайтмадылар. Тау астында бик тирән агулы күл бар, анда кергән кеше шунда ук бата. Тау уртасында дәү бөркет утыра. Кеше затын күрүгә, ул күк йөзен канатлары белән каплый. Кеше затының караңгылыктан куркып, йөрәге ярыла. Ә тау башында дию үзе кешене уты белән көйдереп көлгә калдыра», – ди. Әмма егетне сандугачның бу сүзләре туктатмый. Карт биргән өч ук турында исенә төшерә ул. Сылуны коткарырга егет алга атлый.

Беренче укны күлгә юнәлтә, күл шунда ук корый. Икенче укны тау уртасында утырган дәү бөркеткә төзи, бөркет чыпчыкка әверелә. Өченче угын диюгә җибәрә, дию парга әйләнеп күккә күтәрелә. Шулай итеп, Тимерхан Сылуны коткара һәм әби белән бабай янына кайтып бәхетле гомер кичергәннәр, ди.

**Кадрия ХӘКИМУЛЛИНА,**
*5 б сыйныфы*

Минем гимназиям
**Баш мөхәррир** Алия НУРИСЛАМОВА • **Редакция әгъзалары:** Азалия ӘМИНОВА • Адилә ХАНОВА • Мәрьям РИЗАТДИНОВА • Әминә ШАКИРОВА • Данис ДАМИНОВ • Ләйсән КӘРИМОВА • Камилла ЮСУПОВА • Зәринә СӘХӘБЕТДИНОВА
• **Редактор-координатор:** Э. А. НУРИСЛАМОВА